# «Дары көйдергән яшьлек…»

**(Багышлана Шайхетдинов Дамир Әлтәф улына Балтач районы Югары Шубан авылында яши)**

Әфганстанның шомлы җилләре безнең Югары Шубан авылын да урап үтмәде. Безнең авылда туып үскән лачындай дүрт егеткә дә ул дәһшәтле көннәрнең шаһиты булып, гомерләрен куркыныч астына куеп ут астында йөрергә, дары исен иснәргә туры килә.

Безнең күрше дә яшәүче Шайхетдинов Дамир абый гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килә. Юк, төпчек бала булмый ул. Үзеннән соң туган энеләре Таһир белән Илһамны бик ярата, аларны гел җитәкләп йөри, еласалар юата, уенчыклар ясап бирә, кызыклы китаплар укый.


Шат күңелле, шаян була Дамир абый. Беренчедә укыганда гармун уйнарга өйрәнә, үзе уйнап сәхнәләрдә җырлый. Аның бөтен туганнары җыр-моңга гашыйк.

18 яше тулгач аны Казанга хәрби техника (тягач) йөртергә өйрәнү өчен укырга җибәрәләр. Тырышып укый Дамир абый. Укып бетерүгә, иптәш малаен озату кичәсендә төнлә армиягә чакыру хәбәре килә.

Шулай итеп Дамир абый – мыек та чыкмаган, малайлыктан чыгып кына килгән мәлдә сугыш дигән аждаһа авызына барып керә.



Дамир абый Әфганстанның Саманган провенциясендә яши. Кырыс табигать, корылык, башың пешәрлек эссе. Яшәү җир астына казылып ясалган землянкада, керосин лампасы яктысында туган якка юлланган хатларда... Учак ягып, казан асып ашарга әзерлиләр. Җирле халык белән дус-тату яшиләр, бергәләп фотоларга да төшәләр.




Хәрби операцияләр вакытында үлем белән күзгә - күз очрашулар, саны - санга аерылган иптәшләрне цинк табутларда туган якка озатулар...

Ул хәлләрне Дамир абый сөйли алмый, ,,сөйлә" – дип алҗытсак, хәтирәләргә бирелеп, күз яшьләренә буыла. Кызып китеп авырта башлый.

Ике ел күргән канлы вакыйгалардан төнлә төшләнеп куркып уяна. Торып дарулар эчә. Һәм бу гаиләдә сугыш киноларын карау тыелган.

Дамир абый китапханәнең даими укучысы, телевизор белән дус түгел китапларны күп укый. Һәм биш баласына да китапка мәхәббәт уяткан әти ул.

Дамир абый улларына да ,,Армиягә бармагыз" – дип әйтми. Аның олы улы Райнур абый хезмәт итеп кайтты инде. Хәзерге вакытта Ранил абый хезмәт итә. Тиздән Рүзәл абыйга чират җитәр.

Дамир абыйга тыныч тормышта яшәве ай-һай авыр. Чөнки йөрәгендә мәңге төзәлмәс яра, колагында бомбалар, чинаган самолетлар үкергән тавыш. Чит җирләрдә хәбәрсез югалган, теткәләнгән дуслары төшләренә кереп йөдәтә.

Кичләрен Дамир абый капка төбендә гармунын бер сызып җибәрсә, без - бала-чага – аның тирәсенә җыелабыз. Ул безне җырлата-биетә, кыскасы чирәмлектә бергәләшеп концерт куябыз.

«Сезгә бу афәтләрне күрергә язмасын - ди Дамир абый - илләр тыныч, күкләр гел аяз булсын!»

Дамир абыйның вазыйфасы һәм хәрби исеме: рядовой. Ул «Сугышчы интернационалист» исемле күкрәк билгесе һәм «СССРның хәрби көчләренә 70 ел», «Изге Әфган сугышында катнашканы» өчен медальләре белән бүләкләнә.

Эшләде: Мөхәммәтҗанова Язилә
Раушан кызы  (13 яшь)
Шубан төп гомуми белем мәктәбе
7 нче сыйныф укучысы
Югары Шубан авылы.

